КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 декабрь

г.Казань

№ 1336

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тарихи җирлек территориясен тотрыклы үстерү концепциясен әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 2 февраль, 76 нчы карары белән расланган Тарихи җирлек территориясен тотрыклы үстерү концепциясен әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тарихи җирлек территориясен тотрыклы үстерү концепциясен әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 2 февраль, 76 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 июль, 710 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Тарихи җирлек территориясен тотрыклы үстерү концепциясен әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга субсидияләр бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 эш көнендә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

2.1 пунктның өченче абзацында «30 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләрен «5 нче календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга;

3.2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин